ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына балигъ булмаганнарга автомобиль бензинын сатуны чикләүне билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 95-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары О.М. Воронова, Р.С. Гайнетдинова, М.З. Гарифуллин, Д.З. Зарипов, С.М. Захарова, Ю.З. Камалтынов, Л.Н. Маврина, Р.Р. Нигъмәтуллин, А.А. Чубаров тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасының аерым закон актларына балигъ булмаганнарга автомобиль бензинын сатуны чикләүне билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 95-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәмммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2025 елның 17 июле
№ 350-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
О.М. Воронова, Р.С. Гайнетдинова,
М.З. Гарифуллин, Д.З. Зарипов,
С.М. Захарова, Ю.З. Камалтынов,
Л.Н. Маврина, Р.Р. Нигъмәтуллин,
А.А. Чубаров тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына балигъ булмаганнарга автомобиль бензинын сатуны чикләүне билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7; 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш); 2024, № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш), № 18 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.22 статья өстәргә:

«2.22 статья. **Балигъ булмаганнарга автомобиль бензинын ваклап сатуны чикләүне үтәмәү**

Балигъ булмаганнарга автомобиль бензинын ваклап сатуны, транспорт чарасының ягулык багына автомобиль бензинын салганда уналты яшькә җиткән, транспорт чарасы белән идарә итү хокукына ия булган затларга аны ваклап сатудан тыш, чикләүне үтәмәгән өчен –

гражданнарга – өч меңнән алып биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – утыз меңнән алып илле мең сумга кадәр; юридик затларга йөз меңнән алып йөз илле мең сумга кадәр административ штраф салына.»;

2) 7.1 статьяда «2.11 – 2.21» саннарын «2.11 – 2.22» саннарына алмаштырырга;

3) 8.1 статьяның 14 өлешендә «2.21,» саннарыннан соң «2.22,» саннарын өстәргә.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 7; 2015, № 3, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш), № 49 (I өлеш), аңа «2.21,» саннарыннан соң «2.22,» саннарын өстәп, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

«Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2013, № 10; 2015, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 95 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле $7^3$ статья өстәп, үзгәреш кертергә:

«$7^3$ статья. **Балигъ булмаганнарга автомобиль бензинын ваклап сатуны чикләү**»

Балигъ булмаганнарга автомобиль бензинын ваклап сату, транспорт чарасының ягулык багына автомобиль бензинын салганда уналты яшькә җиткән, транспорт чарасы белән идарә итү хокукына ия булган затларга аны ваклап сатудан тыш, рөхсәт ителми.».

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына балигъ булмаганнарга автомобиль бензинын сатуны чикләүне билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

Балалар мәнфәгатьләрендә дәүләт сәясәте максатларының берсе – балаларны аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә тискәре йогынты ясаучы факторлардан саклау («Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясы (алга таба – 124-ФЗ номерлы Федераль закон).

124-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясындагы 2 пункты нигезендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарының Россия Федерациясендә бала хокукларының гарантияләрен башкару вәкаләтләренә балалар мәнфәгатьләрендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру керә. Россия Федерациясе субъекты балалар сәламәтлегенә зыян китерүне кисәтү буенча төрле чаралар күрергә мөмкин.

Юл-транспорт һәлакәтләрендә балаларның җәрәхәтләнүен киметү һәм техник хәрәкәтләнү чараларында (мопедларда, квадроциклларда, питбайкларда һәм башка мототранспортта) гомумфайдаланудагы юлларга чыгучы балигъ булмаганнарның юлларда һәлак булуын булдырмау максатларында закон проекты белән балигъ булмаганнарга автомобиль бензинын сатуны, транспорт чарасының ягулык багына автомобиль бензинын салганда уналты яшькә җиткән, транспорт чарасы белән идарә итү хокукына ия булган затларга аны ваклап сатудан тыш, чикләүне кертү тәкъдим ителә.

Мондый чикләүнең зарурлыгы балаларның югарыда күрсәтелгән техник хәрәкәтләнү чаралары белән кызыксынуның артуына, имин хәрәкәт итү турында белемнәре булмаган (экипировкада экономияләү һәм башкалар), әмма, кагыйдәләрне бозып, автомобиль юлларыннан файдалану өчен билгеләнмәгән мототранспортта гомумфайдаланудагы юлларга чыга торган өйрәнчекләр санының артуына бәйле.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Дәүләт автомобиль инспекциясе идарәсе мәгълүматы буенча мототранспорт катнашында 2023 елда – 236, 2024 елда 234 юл-транспорт һәлакәте (алга таба – ДТП) теркәлгән.

2024 елда балигъ булмаганнар мототранспорт белән идарә иткәндә барлыкка килгән ДТП саны 2023 ел белән чагыштырганда – 40 процентка, һәлак булучылар саны 3 тапкырга арткан.

2023 елда 18 яшькә кадәрге балалар катнашында 39 ДТП – (2 һәлак булган, 47 яраланган), шул исәптән 16 яшькә кадәрге балалар катнашында 25 ДТП теркәлгән (1 һәлак булган, 30 яраланган) теркәлгән.

2023 елда 18 яшькә кадәрге балалар катнашында 54 ДТП – (6 һәлак булган, 56 яраланган), шул исәптән 16 яшькә кадәрге балалар катнашында 35 ДТП теркәлгән (3 һәлак булган, 36 яраланган) теркәлгән.

2025 елның 25 июненә Татарстан Республикасында мототранспорт катнашында 97 ДТП теркәлгән, шул исәптән 18 яшькә кадәрге балалар катнашында 27 (1 һәлак булган, 32 яраланган), шуларның 15 – 16 яшькә кадәрге балалар катнашында (1 һәлак булган, 15 яраланган).

Закон проекты белән Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына югарыда күрсәтелгән чикләүне үтәмәгән өчен түбәндәге җаваплылыкны билгели торган 2.22 статьяны өстәү тәкъдим ителә: гражданнарга – өч меңнән алып биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – утыз меңнән алып илле мең сумга кадәр; юридик затларга йөз меңнән алып йөз илле мең сумга кадәр күләмдә штраф салына. Яңа 2.22 статьяда карала торган административ хокук бозулар турында эшләр кузгату компетенциясен – җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларына, ә күрсәтелгән эшләрне карау компетенциясен җәмәгать судьяларына беркетү тәкъдим ителә.

Шундый ук үзгәрешне «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына да кертү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына балигъ булмаганнарга автомобиль бензинын сатуны чикләүне билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына балигъ булмаганнарга автомобиль бензинын сатуны чикләүне билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә яңаларын кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына балигъ булмаганнарга автомобиль бензинын сатуны чикләүне билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына балигъ булмаганнарга автомобиль бензинын сатуны чикләүне билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнарны таләп итми.